КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 14 июль г.Казань № 676

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 гыйнвар, 60 нчы; 2022 ел, 11 май, 430 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2022 – 2025 еллар. Тормышка ашыру этапларга бүленми»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләме</td>
<td>Программаны финанслауның гомуми күләме 3 896 040,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 337 983,2 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 488 562,1 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы – 3 069 494,7 мең сум.<br>(мең сум)
<table>
<tr><th>Ел</th><th>Барысы</th><th>Татарстан Республика-сы бюджеты акчасы</th><th>Федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаш-тырыла торган акча</th><th>Бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча</th></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 074 919,0</td><td>121 987,2</td><td>255 312,1</td><td>1 697 619,7</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 016 621,5*</td><td>112 434,0*</td><td>123 000,0*</td><td>781 187,5*</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>804 499,5*</td><td>103 562,0*</td><td>110 250,0*</td><td>590 687,5*</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>Барысы</td><td>3 896 040,0*</td><td>337 983,2*</td><td>488 562,1*</td><td>3 069 494,7*</td></tr>
</table>
* Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен һәм сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары ихтыяҗларын исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.<br>Программаның федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин ителеш күләме ел саен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү максатларында төбәк программаларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә»;</td>
</tr>
</table>

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Програм-маның максатла-рын һәм бурыч-ларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру 2025 елга түбәндәге нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 4,3 млрд.сум;<br>булдырылган эш урыннары саны (тупланган нәтиҗә белән) – 655 берәмлек; |

| | |
|---|---|
| һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 119,28 млрд.сум;<br>Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыру (керү) (тупланган нәтиҗә белән) («Төп фондларның (акчаның) һәм финанс булмаган башка активларның булу-булмавы һәм хәрәкәте турында мәгълүматлар» дигән 11 нче федераль статистик күзәтү формасының 4 графасындагы 07 нче юлы) – 2,96 млрд.сум;<br>2022 елда финанс ярдәме күрсәтелгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары саны – кимендә 7»; |

Программаның I бүлегендә:
2 бүлекчәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы икътисадының сәнәгать секторы торышы.
Сәнәгать үсешендәге тенденцияләр

2020 елда яңа коронавирус йогышлы инфекциясе таралу аркасында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе икътисады тулаем алганда сорауга һәм тәкъдимгә масштаблы чикләү кертүгә, глобаль кооперация һәм сәүдә элемтәләре бозылуга, эшлекле активлыкны киметүгә, нефть бәяләрнең һәм валюта курсының волатильлегенә, ОПЕК+ килешү кысаларында нефть чыгаруны чикләүгә шактый бәйле булып калды.

2020 елда сәнәгать җитештерүе индексы 2019 ел дәрәҗәсенә карата 96,4 процент, төяп җибәрелгән продукция күләме 2 721,2 млрд.сум тәшкил итте.

Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2019 ел дәрәҗәсенә карата 89,5 процент, эшкәртү производстволарында – 102,0 процент, электр энергиясе, газ, пар, һаваны кондицияләү белән тәэмин итү – 85,4 процент, су белән тәэмин итү, су чыгару, калдыклар җыюны һәм утильләштерүне, пычракларны бетерү эшчәнлеген оештыру 98,4 процент тәшкил итте.

Дөньякүләм базарларында энергия ресурсларына бәяләрнең югары волатильлегенә, валюта курсына һәм катлаулы эпидемия вәзгыятенә карамастан, федераль һәм республика ярдәм чаралары ярдәме, предприятиеләр эшчәнлеген активлаштыру нәтиҗәсендә 2021 ел республика икътисадын пандемиягә кадәрге дәрәҗәгә кире кайтару белән характерлана.

2021 ел йомгаклары буенча сәнәгать җитештерүе индексы 2020 елның шул ук чорына 108,5 процент, төяп җибәрелгән продукция күләме 4 005,9 млрд.сум тәшкил итте. Эшкәртү производстволарында җитештерү индексы 2020 ел дәрәҗәсенә карата 110,8 процент тәшкил итте.

Сәнәгать структурасында файдалы казылмалар чыгару өлеше – 25,1 процент, эшкәртү производстволары – 69,5 процент, электр энергиясе, газ һәм пар, һаваны кондицияләү белән тәэмин итү – 3,9 процент, су белән тәэмин итү, су чыгару, калдыклар җыюны һәм утильләштерүне, пычракларны бетерү эшчәнлеге 1,4 процент тәшкил итте.

Файдалы казылмалар чыгаруда җитештерү индексы 2020 ел дәрәҗәсенә карата 104,1 процент, эшкәртү производстволарында – 110,8 процент, электр энергиясе, газ, пар, һаваны кондицияләү белән тәэмин итү – 109,9 процент, су белән тәэмин итү, су чыгару, калдыклар җыюны һәм утильләштерүне, пычракларны бетерү эшчәнлеген оештыру 145,5 процент тәшкил итте.

Икътисадый үсешнең төп факторлары: сәнәгать җитештерүенең яңа куәтләрен гамәлгә кертү; система барлыкка китерүче предприятиеләрнең йөкләнешен арттыру; нефть продуктларын, химия продукциясен, машиналар чыгару күләмнәрен арттыру; нефть чыгаруны этаплап арттыру, шулай ук кулланучылар базарын торгызу.

2022 елда Татарстан Республикасының сәнәгатен үстерүгә тышкы сәяси конъюнктура зур йогынты ясый. Чит ил капиталы булган кайбер предприятиеләр эшчәнлеген туктаттылар. Яңа логистик һәм җитештерү чылбырларын төзү зарурлыгы мөһим сынау булды.

2022 елның гыйнвары – маенда сәнәгать җитештерүе индексы 108,4 процент, үз җитештерүдәге төяп җибәрелгән торварлар күләме, үз көчләре белән башкарлыган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр 1 995,6 млрд.сум тәшкил итте.»;

3 бүлекчәнең өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Нәтиҗәдә төяп җибәрелгән продукциянең гомуми күләмендә эшкәртү производстволары өлеше 2021 ел йомгаклары буенча иң күбе 69,5 процент тәшкил итте.»;

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның максаты, бурычлары һәм аны тормышка ашырудан көтелә торган төп соңгы нәтиҗәләре тасвирламасы, аны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаның төп максаты – глобаль масштабта конкурентлыкка сәләтле, озак сроклы динамик үсеш потенциалына ия һәм Татарстан Республикасының стратегик өстенлекләрен тормышка ашыруны тәэмин итә торган сәнәгатьне үстерү өчен шартлар тудыру.

Әлеге максатка ирешү түбәндәге төп бурычларны хәл итү юлы белән тәэмин ителәчәк:

1. Яңа җитештерүләр төзүне тәэмин итү өчен коммуналь инфраструктураны үстерүгә булышлык күрсәтү.

2. Перспективалы конкуренциягә сәләтле продукция җитештерү өчен модернизацияләү һәм яңадан техник коралландыру проектларын тормышка ашыруны стимуллаштыру.

3. Сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларына әйләнеш акчаларын тулыландыру максатларында төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү өчен грантлар рәвешендә финанс ярдәме күрсәтү.

4. Гражданлык билгеләнешендәге продукция җитештерү өчен оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре потенциалыннан файдалануны стимуллаштыру.

Куелган бурычларны хәл итүне түбәндәге чараларны үткәрү юлы белән гамәлгә ашыру максатка ярашлы була:

1) инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында коммуналь инфраструктурага тоташтыру буенча ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар хезмәтләре өчен түләүгә сәнәгать предприятиеләре чыгымнарының бер өлешен каплау;

2) сәнәгать предприятиеләренә Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә беренче кертемне (авансны) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау;

3) сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһаз сатып алуга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау;

4) сәнәгатьне үстерү төбәк фонды эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү (докапитализацияләү);

5) оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына гражданлык билгеләнешендәге продукция чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр бирү.

Сәнәгатьнең эшкәртү тармакларындагы республика предприятиеләренең инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен финанслар җәлеп итү максатында әлеге проектларны Россия Федерациясе сәнәгатен үстерүнең гамәлдәге һәм планлаштырыла торган программаларына кертү буенча эш башкарылачак.

2025 елга ирешергә планлаштырылган Программаның төп күрсәткечләре:

Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 4,3 млрд.сум;

булдырылган эш урыннары саны (тупланган нәтиҗә белән) – 655 берәмлек;

Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 119,28 млрд.сум;

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыру (керү) (тупланган нәтиҗә белән) («Төп фондларның (акчаның) һәм финанс булмаган башка активларның булу-булмавы һәм хәрәкәте турында мәгълүматлар» дигән 11 нче федераль статистик күзәтү формасының 4 графасындагы 07 нче юлы) – 2,96 млрд.сум.

Сәнәгатьне үстерү төбәк фонды эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү (докапитализацияләү) нәтиҗәлелегенең төп күрсәткече – 2022 елда финанс ярдәме күрсәтелгән сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектлары саны, кимендә 7.

Программаның максатлары, бурычлары, чаралары яктылыгында нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары Программа кушымтасында китерелде.

Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары

Программаны тормышка ашыру срогы 2022 – 2025 еллар чорына исәпләнде. Тормышка ашыру этапларга бүленми.

Программа чаралары ел саен үткән чор өчен программа чараларын тормышка ашыруның ресурслар белән тәэмин ителешен һәм нәтиҗәләрен исәпкә алып актуальләштерелә.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 3 896 040,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 337 983,2 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 488 562,1 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы – 3 069 494,7 мең сум.

(мең сум)

| Ел | Барысы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | Федераль бюджеттан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча | Бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча |
|---|---|---|---|---|
| 2022 | 2 074 919,0 | 121 987,2 | 255 312,1 | 1 697 619,7 |
| 2023 | 1 016 621,5* | 112 434,0* | 123 000,0* | 781 187,5* |
| 2024 | 804 499,5* | 103 562,0* | 110 250,0* | 590 687,5* |
| 2025 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| Барысы | 3 896 040,0* | 337 983,2* | 488 562,1* | 3 069 494,7* |

*Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше күләме федераль бюджет акчасы исәбеннән ел саен сәнәгатьне үстерү төбәк программаларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча билгеләнә.»;

Программаның VI бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VI. Программаның бюджет нәтиҗәлелеге

Программаның бюджет нәтиҗәлелеге исәп-хисабы түбәндәге таблицада китерелде:

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Татарстан Республикасы бюджеты өчен нәтиҗәлелек | | | | Федераль бюджет өчен нәтиҗәлелек | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1. | Программаны тормышка ашыруга бюджет инвестицияләре, мең сум | 121 987,2 | 112 434,0 | 103 562,0 | 0,0 | 255 312,1 | 82 000,0 | 73 500,0 | 0,0 |
| 2. | Программаны тормышка ашырудан бюджетка салым керемнәре ($N_i$), мең сум, | 302 571,5 | 139 857,0 | 113 660,0 | 0,0 | 99 144,6 | 95 660,0 | 75 120,0 | 0,0 |
| | шулардан: | | | | | | | | |
| | табышка салым, мең сум | 218 711,9 | 25 148,0 | 19 748,0 | 0,0 | 38 596,2 | 4 437,8 | 3 485,0 | 0,0 |
| | Өстәлгән салымга керем, мең сум | | | | | 60 548,4 | 91 222,3 | 71 635,5 | |
| | НДФЛ, мең сум | 49 017,9 | 73 850,0 | 57 994,0 | 0,0 | | | | 0,0 |
| | мөлкәткә салым, мең сум | 34 841,7 | 40 859,0 | 35 918,0 | 0,0 | | | | 0,0 |
| 3. | Программаның турыдан-туры еллык бюджет нәтиҗәлелеге ($Е_{бн}$), процент | 90 | 41 | 34 | 0 | 20 | 20 | 15 | 0 |
| 4. | Турыдан-туры интеграль бюджет нәтиҗәлелеге ($И_{бэ}$), процент | | | | 165 | | | | 55 |

Бюджет нәтиҗәлелеген исәпләгәндә ясалган төп рөхсәт итүләр:

Программаны тормышка ашыру барышында башкарыла торган, Татарстан Республикасы предприятиеләренең гамәлдәге производстволарын модернизация-

ләүгә юнәлдерелгән проектлар;

проектларны тормышка ашырган предприятиеләрдә продукция сатудан кергән табыш кертелгән акча суммасыннан фонд акчасын файдалану коэффициенты нигезендә артачак;

12 айга өстәлгән кыйммәткә салым буенча чигереп калулар өлеше салым базасыннан исәпләнгән салым суммасыннан 88,9 процент тәшкил итә;

продукция сатудан табышның рентабельлеге 3 процент тәшкил итә;

хезмәт хакы фонды продукция чыгару күләменнән 15 процент тәшкил итә;

фонд акчасын файдалану коэффициенты 3 кә тигез;

«Сәнәгатьне үстерү төбәк фонды эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү (докапитализацияләү) чарасы буенча әйләнеш акчаларын тулыландыру максатларында төзелгән кредит шартнамәләре буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен компенсацияләү өчен грантлар рәвешендә бирелгән акча табышка салым буенча салым салына торган базаны арттыра;

«Гражданлык билгеләнешендәге продукция чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына субсидияләр бирү» чарасы буенча исәпләү салымнарның түләү өчен фаразлана торган өлешеннән чыгып гамәлгә ашырылды.»;

Программаның кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин